**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7459**
**22.12.2022**

2023 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урынынnan файдалану өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясының 3, 4 өлешләре, 158 статьясының 4 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 31, 36 пунктлары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы приказы белән расланган дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләр, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы приказы белән расланган күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук шундый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә, халык хокукларын һәм ихтыяҗларын яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы Карары, Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап

тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен кушымтада каралганча билгеләргә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме торак урынны карап тоту буенча күрсәтелә торган хезмәтләр составына һәм күпфатирлы йортның конструктив үзенчәлекләренә бәйле рәвештә исәпләнүне һәм үзгәртелүне билгеләргә.

3. Торак урынны наемга алу өчен түләү күләме, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезләмәдә каралган коэффициентларны кулланып, торак урынның сыйфатына һәм төзекләндерелүенә, йортның урнашу урынына бәйле рәвештә билгеләнә.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 22 декабрендәге
7459 номерлы карарына
кушымта

2023 елга дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләме

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | 01.01.2023 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак урынны наемга алу өчен түләүнең база күләме | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 7,12* |
| 2. | Торак фонды белән идарә итү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,25 |
| 3. | Гомуми файдалану урыннарын санитар карап тоту, шул исәптән: | | |
| 3.1. | - йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын җыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,15 |
| 3.2. | - йорт яны территориясен җыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,30 |
| 3.3. | - чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,45 |
| 3.4. | - дератизация (дезинсекция) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,21 |
| 4. | Төзелеш корылмаларын һәм биналарның инженерлык системаларын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү, шул исәптән: | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.1. | - торак биналар һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,40 |
| 4.2. | - лифтлар | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,54 |
| 4.3. | - йорт эчендәге электр челтәрләре һәм электр җиһазлары | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,95 |
| 4.4. | - йорт эчендәге газ челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,31 |
| 4.5. | - йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары (бойлер булган) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,87 |
| 4.6. | - йорт эчендәге үзәктән җылыту челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,87 |
| 4.7. | телевидениене коллектив кабул итү системалары (СКПТ) (хезмәт күрсәтелгән очракта) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,55 |
| 4.8. | - янгынга каршы автоматика системасы (хезмәт күрсәтелгән очракта) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,15 |
| 4.9. | - домофоннар | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,55 |

Искәрмә:
* - Түләүнең туры килү коэффициентын исәпкә алып.
Халыкка торак урынны карап тоту һәм ремонтлау хезмәтләре өчен түләү күләме өстәмә кыйммәткә салымнан тыш билгеләнгән.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева